МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА
И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ
ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

17.07.2019 № 319

Казан ш.

Журналистларны Татарстан
Республикасы Транспорт һәм юл
хуҗалыгы министрлыгы каршында
аккредитацияләү кагыйдәләрен раслау
турында

«Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2124-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 48 статьясы нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Журналистларны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршында аккредитацияләү кагыйдәләрен расларга.
2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Эшләр белән идарә итүче А.Р. Галимбековка йөкләргә.

Министр Л.Р. Сафин

Татарстан Республикасы
Транспорт һәм юл хуҗалыгы
министрлыгының 17.07.2019
№ 319 боерыгы белән расланган

# Журналистларны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршында аккредитацияләү кагыйдәләре

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Кагыйдәләр «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2124-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 48 статьясы нигезендә массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларын Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршында аккредитацияләү (алга таба - аккредитация, Министрлык) процедурасын регламентлый.

1.2. Аккредитация сроксыз нигездә гамәлгә ашырыла. Массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе теләге нигезендә аккредитацияләү конкрет редакция йөкләмәсен үтәү буенча яки аккредитацияләнгән журналистны ул булмаган вакытка алыштырып тору өчен билгеле бер вакытка да (вакытлы аккредитация) эшәнергә мөмкин.

## II. Аккредитацияләнү хокукы

2.1. Милек формасыннан һәм гамәлгә куючылар составыннан бәйсез рәвештә барлык массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре дә, шулай ук чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары да аккредитация узу хокукына ия. Чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларын аккредитацияләү өчен аның Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгы каршында аккредитация узганлыгын раслау шарт.

## III. Аккредитацияләү тәртибе

3.1. Аккредитацияләүгә Министрлыкка массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе имзасы куелган гариза Министрлык тарафынан әлеге гаризаның алыну фактын, көнен һәм вакытын раслау мөмкин булган теләсә кайсы ысул белән чара башланганчы бер эш көненнән дә соңга калмыйча бирелә.

3.2. Гаризада журналистның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булганда), аның вазыйфасы, эш һәм кәрәзле телефоннары номеры, электрон почтасы адресы, массакүләм мәгълүмат чарасының тулы исеме, массакүләм мәгълүмат чарасының теркәлүгә куелуы турындагы мәгълүмат номеры һәм көне күрсәтелә. Чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларын аккредитацияләгәндә өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгы каршында аккредитация узганлыкны раслаучы документларның күчермәләре дә бирелә.

3.3. Министрлыкка әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән сроктан соңрак кергән гаризалар, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.2 пункты таләпләренә туры килми торган гаризалар каралмый.

3.4. Аккредитацияләү (аккредитацияләүдән баш тарту) турындагы карар Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министры (аның вазыйфаларын башкаручы зат) тарафыннан гариза кергән көнне кабул ителә. Мондый карар тиешле чара башланганчы ике сәгатьтән дә соңга калмыйча, гариза җибәргән массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясенә, аны редакция тарафыннан алу фактын, көнен һәм вакытын расларга мөмкинлек бирүче теләсә кайсы ысул белән җиткерелә. Ашыгыч чара үткәрелгән очракта, кабул ителгән карар турында мәгълүмат мондый чара башланганчы җиткерелә.

3.5. Массакүләм мәгълүмат чаралары махсус характерда булса (реклама, белешмәлек, күңел ачу) аккредитацияләү башкарылмый.

## IV. Аккредитацияләнгән жуналистларның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Аккредитацияләнгән журналистлар хокуклы:

чараларда катнашырга;

чара турында Министрлыкта булган рәсми документларның күчермәләрен алырга (көн тәртибе, пресс-релизлар, мәгълүмати-белешмәлек, статистика, аналитика һәм башка материаллар);

бастырып чыгару өчен каралган мәгълүмати-белешмәлек материаллары белән танышырга;

Россия Федерациясе законнарында каралган башка хокуклар.

4.2. Аккредитацияләнгән журналистлар бурычлы:

чара регламентларын сакларга һәм аның барышына катышмаска, әгәр дә ул махсус массакүлм мәгълүмат чаралары өчен планлаштырылмаган булса;

чарада катнашучылар эшчәнлегенә комачауламаска;

үз басмаларында (эфир эшчәнлегендә) Министрлык тарафыннан бирелгән пресс-релизларны, мәгълүмати-белешмәлек, статистика, аналитика һәм башка метериалларны файдаланганда мәгълүмат чыганагына сылтама бирергә;

үз профессиональ эшчәнлекләрен гамәлгә ашырганда Министрлык эшчәнлеге турында дөреслеккә туры килми торган мәгълүматлар таратмаска.